**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «24» апреленнән № 54-417

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 10 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставының 53 статьясындагы 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Фасаховның шәхси гаризасы буенча, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Шәхси гаризасы нигезендә үз теләге буенча, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыннан, Фасахов Ринат Рифгат улының отставкасын кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Фасахов Ринат Рифгат улының вәкаләтләрен 2025 елның 24 апреленнән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов